ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2023 г. Казань № 705-54/т-2023

«Казан» халыкара аэропорты территориясендә «Авиэйшн Лоджистик Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан һава судноларын авиация ягулыгы белән тәэмин итү хезмәте күрсәтүгә 2024 елга максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләү турында

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларында, аэропортларында табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләре турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы һәм «Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салуы өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең 2014 елның 31 октябрендәге 238-т/2 номерлы боерыгы белән расланган Аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә җыемнарны һәм тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу мәсьәләсе буенча методик күрсәтмәләр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 15.12.2023 №59-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казан» халыкара аэропорты территориясендә «Авиэйшн Лоджистик Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан һава судноларын авиация ягулыгы белән тәэмин итү хезмәте күрсәтүгә тоннасы өчен 1176,73 сум күләмендә

(өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тариф 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев